| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

04.09.2019 ел Баулы шәһәре №257

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2019 елның
19 апрелендә кабул ителгән №107 карары
белән расланган, 2019 елның 10 июнендәге
162нче карар, 2019 елның 24 июлендәге
218нче карар белән үзгәрешләр кертелгән
Тезелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 27 сентябрендә кабул ителгән «Тезелешкә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү өчен кирәкле документларны электрон формада җибәрү турында»гы 729нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 19 апрелендә кабул ителгән №107 карары белән расланган, 2019 елның 10 июнендәге 162нче карар, 2019 елның 24 июлендәге 218нче карар белән үзгәрешләр кертелгән Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

2 «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегендә:

2.5. пунктның икенче баганасында:

2 пунктчаның беренче абзацында) «ачык сервитут» сүзләреннән соң «шулай ук күрсәтелгән җир участогы формалаштыру һәм җир участогының шәһәр төзелеше планы бирүгә нигез булган территориянең кадастр планында җир участогын һәм җир участокларын урнаштыру схемасы (Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы 57.3 статьясы 1.1 өлешендә каралган очракта) яки скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда)»;

2) пунктчаның икенче абзацы; а), в), г); пунктчалары; 4), 6), 7), 8), 9), 10), 11), 12) пунктларын «яисә скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда)» сүзләре белән тулыландырырга;

5) пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп коруга нигез булган проект документлары, шул исәптән әлеге проект документлары белән, линияле объектларны да кертеп, капиталь төзелешнең башка объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – Шәһәр төзелеше кодексы) 48нче статьясы 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), экспертизасының уңай бәяләмәсе, әгәр мондый проект документлары Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы нигезендә экспертиза үтәргә тиеш булса, Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы 3.4. өлешендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы 6нчы өлешендә каралган очракларда, проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе яки аның скан-күчермәсе (электрон форма тутырганда);

а) проект документациясен әзерләүне гамәлгә ашыручы затларның әгъзалыгына нигезләнгән үзлегеннән көйләнешле оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән һәм әлеге зат Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җәлеп иткән архитектура-төзелеш проектлавын оештыру буенча баш белгеч вазыйфасындагы белгеч тарафыннан расланган проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы 3.8. өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе яки аның скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда), Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы 3.8. өлеше нигезендә, проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта.

б) башкарма хакимият органы яки проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан бирелгән, проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы 39 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе яки аның скан-күчермәсе (электрон форманы тутырганда), проект документларына экспертиза үткәрү барышында Шәһәр төзелеше кодексының 49нчы статьясы 39 өлеше нигезендә үзгәрешләр кертелгән очракта.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров